ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының $11^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» 561-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары С.М. Захарова, Р.У. Әхмәтов, А.И. Зыятдинов, А.С. Созинов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының $11^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» 561-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 6 июне
№ 2514-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
С.М. Захарова,
Р.У. Әхмәтов,
А.И. Зыятдинов,
А.С. Созинов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының $11^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $11^1$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 86 (I өлеш) № 92 (I өлеш), аны түбәндәге редациядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

**«$11^1$ статья. Татарстан Республикасында сатып алуларны оештыру**

«Татарстанның медицина техникасы һәм фармациясе» дәүләт унитар предприятиесе бердәнбер тәэмин итүче (башкаручы) буларак Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле органын, аңа ведомство буйсынуындагы оешмаларны дарулар, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары, медицина әйберләре, чыгым материаллары, дезинфекция чаралары, шулай ук тиешле товарларны саклау һәм илтеп тапшыру хезмәтләре, медицина әйберләрен ремонтлау һәм аларга техник хезмәт күрсәтү эшләре белән тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 11[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 444-ФЗ номерлы Федераль закон белән 2024 елның 1 июленнән «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның бердәнбер тәэмин итүчедән (подрядчыдан, башкаручыдан) сатып алуны гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы нигезләмәләренә өстәмәләр кертелә. Кертелә торган үзгәрешләр нигезендә Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектының дәүләт учреждениеләре (Россия Федерациясе субъекты составына керә торган муниципаль берәмлекләрнең муниципаль учреждениеләре) тарафыннан дарулар, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары, медицина әйберләре, чыгым материаллары, дезинфекция чаралары, шулай ук тиешле товарларны саклау һәм илтеп тапшыру буенча хезмәтләр, медицина әйберләрен ремонтлау һәм аларга техник хезмәт күрсәтү эшләре тиешле Россия Федерациясе субъектының дәүләт унитар предприятиесеннән йә акцияләренең йөз проценты тиешле Россия Федерациясе субъектына караган акционер җәмгыятеннән сатып алу гамәлгә ашырылган очракта, бердәнбер тәэмин итүчедән сатып алу рөхсәт ителә.

Хәзерге вакытта «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) 11[1] статьясындагы 2 өлеше Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле органының ведомство буйсынуындагы оешмаларын дарулар, медицина әйберләре, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары, дезинфекция чаралары һәм башкалар белән тәэмин итү максатларында бердәнбер тәэмин итүче (башкаручы) буларак вәкаләтне «Татарстан медицина техникасы һәм фармациясе» дәүләт унитар предприятиесе гамәлгә ашыра, әгәр Россия Федерациясе норматив хокукый акты белән дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан Россия Федерациясе субъектының закон чыгару акты нигезендә бердәнбер тәэмин итүче вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мөмкинлеге билгеләнгән булса.

Федераль законнардагы үзгәрешләрне исәпкә алып, 2024 елның 1 июленнән «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү

өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешенә өстәмәләр кертә торган 6.1 пунктында кулланыла торган төшенчәләргә таянып, Татарстан Республикасы Законының 11[1] статьясын яңа редакциядә бәян итү тәкъдим ителә.

Мондый очракта 11[1] статьясы нигезләмәләре «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның да, «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» 223-ФЗ номерлы Федераль законның да йогынтысына эләгәчәк.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының $11^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының $11^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының $11^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының $11^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.